| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |
|---|---|

К А Р А РЫ

2021 елның 11 нче ноябреннән 40 нчы номерлы

"Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә бюджет процессы турында" нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 нче ноябрендәге 155 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә бюджет процессы турында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Нигезләмәнең 13 нче статьясындагы 2 нче пунктының 4 нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;";

1.2. Нигезләмәнең 13 нче статьясындагы 3 нче пунктының 5 нче пунктчасына "Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш" сүзләрен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 15 нче статьясындагы 2 нче пунктының 2 нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;";

1.4. Нигезләмәнең 35 нче статьясындагы 27 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "кредит (займ) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы шартнамәдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору шарты белән бирелә.";

1.5. Нигезләмәнең 41 гче статьясындагы 1 өлеше:

1) түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар;";

2) өченче – дүртенче абзацларны дүртенче – бишенче абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Бөрешле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Бөрешле авыл җирлеге" бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А. Смирнова